**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 28 нче мартыннан № 34-129

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында»гы 2021 елның 28 декабрендәге 17-62 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законнары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 28 декабрендәге 17-62 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 19.12.2023 №32-125; карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 1 пункты 1.9. Нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) планлаштыру структурасы элементлары (зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, гражданнар тарафыннан бакчачылык яисә үз ихтыяҗлары өчен яшелчәчелек алып бару территориясе);».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм интернет-телекоммуникация челтәрендәге Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү комиссиясе рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Яңа Чишмә авыл
җирлеге Башлыгы урынбасары О.И. Лазарева